**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 21 март № 168

г. Казань

Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген алып бару тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 3 июль, ФЗ-277 нче Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгын Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген (алга таба – Исемлек) алып баруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген алып бару тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

3. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру вәкаләтләре йөкләнгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына әлеге карарның 2 нче пункты белән расланган тәртип нигезендә Исемлеккә кертү өчен

мәгълүматларны 2017 елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибен билгеләргә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 29 март, 199 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче; 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; 2016 ел, 6 август, 533 нче; 2016 ел, 12 декабрь, 918 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4.1.18 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.18. Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген алып бара.».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары вәкаләтләренең бердәм реестры турында» 2010 ел, 29 март, 199 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 21 март, 168 нче карары белән расланды

# Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген алып бару тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген (алга таба – Исемлек) алып бару кагыйдәләрен билгели.

1.2. Исемлекне алып бару Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Исемлекне тотучы) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Исемлекне алып бару түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төренә (алга таба – исәпкә алу объекты) теркәү санын куеп, әлеге Тәртипнең 1.6 нчы пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны Исемлеккә кертү;

исәпкә алу объекты турында үзгәргән мәгълүматларны Исемлеккә кертү (мәгълүматларны яңарту);

исәпкә алу объектын Иесмлектән чыгару.

1.4. Исемлекне алып бару электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

1.5. Исемлек бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада китерелгән форма буенча алып барыла.

1.6. Исемлектә түбәндәге мәгълүматлар була:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы гамәлгә ашыра торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрен теркәү саны;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы гамәлгә ашыра торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре исеме;

төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) әлеге төрен гамәлгә ашыру вәкаләтенә ия булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы исеме;

төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы вәкаләте исеме;

төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны күздә тоткан федераль законның (башка норматив хокукый актның) билгеле нигезләмәләрен (статьяларын, пунктларын, абзацларын) күрсәтеп, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентны раслау яки

әлеге административ регламентка үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының норматив хокукый акты исеме, кабул итү көне, теркәү саны.

Исемлек Исемлекне тотучының рәсми сайтында урнаштырыла һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша һәркем өчен файдалана алырлык була.

2. Исәпкә алу объектын Исемлеккә кертү тәртибе

2.1. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру вәкаләте бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы (алга таба – Орган) төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламент кабул ителгән көннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча аның күчермәсен һәм бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада китерелгән форма буенча исәпкә алу объектын Исемлеккә кертү турындагы гаризаны Исемлекне тотучыга җибәрә.

2.2. Исемлекне тотучы төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламент күчермәсен һәм исәпкә алу объектын Исемлеккә кертү турындагы гаризаны алган көннән соң 10 эш көне эчендә:

кертелгән документларның тулылыгын тикшерүне оештыра;

исәпкә алу объектына теркәү санын куя;

тапшырылган мәгълүматларны Исемлеккә кертә;

Органга бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада китерелгән форма буенча исәпкә алу объектын Исемлеккә кертү турында хәбәрнамә җибәрә.

2.3. Исемлекне тотучы Исемлеккә кертелергә тиешле исәпкә алу объекты турында җитми торган белешмәләрне һәм Исемлекне тотучының соратуын алган көннән соң 10 эш көне эчендә Орган тапшыра торган аңлатма мәгълүматны соратып ала. Исәпкә алу объектын кертү процедурасы соратуны җибәргән көннән туктатылып тора һәм барлык кирәкле мәгълүматны алганнан соң яңартыла.

2.4. Исәпкә алу объектын теркәү саны исәпкә алу объектының дүрт урынлы тәртип саныннан гыйбарәт.

3. Исәпкә алу объекты турында үзгәргән мәгълүматларны Исемлеккә кертү һәм исәпкә алу объектын Исемлектән чыгару тәртибе

3.1. Бу Тәртипнең 1.6 нчы пунктындагы икенче-бишенче абзацларда күрсәтелгән исәпкә алу объекты турындагы мәгълүматлар үзгәргән очракта, Орган тиешле мәгълүматлар үзгәргән көннән соң биш эш көне эчендә Исемлекне тотучыга бу турыда язма рәвештә хәбәр итә.

3.2. Исемлекне тотучы бу Тәртипнең 3.1 нче пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң ике эш көне эчендә үзгәрешләрне Исемлеккә кертә.

3.3. Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны күздә тоткан федераль закон (башка норматив хокукый акт) гамәлдән чыгарылганда, Орган төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны күздә тоткан федераль закон

(башка норматив хокукый акт) гамәлдән чыгарылган дип танылган көннән соң биш эш көне эчендә Исемлекне тотучыга бу турыда язма рәвештә хәбәр итә.

3.4. Исемлекне тотучы әлеге Тәртипнең 3.3 нче пунктында күрсәтелгән хәбәрнамәне алганнан соң ике эш көне эчендә исәпкә алу объектын Исемлектән чыгара.

3.5. Исемлектән чыгарылган исәпкә алу объектын теркәү саны алга таба файдаланылмый.

Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген алып бару тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеге**

| Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрен теркәү саны | Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре исеме | Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) әлеге төрен гамәлгә ашыру вәкаләтенә ия булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы исеме | Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы вәкаләте исеме | Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны күздә тоткан федераль закон (башка норматив хокукый акт), билгеле нигезләмәләрен (статьяларын, пунктларын, абзацларын) күрсәтелгән реквизитларын кертеп, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты, төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентны раслау яки әлеге административ регламентка үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының норматив хокукый акты исеме |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген алып бару тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
икътисад министры
______________________
(Ф.И.Ат.ис.)

**Татарстан Республикасында
төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлегенә кертү турында
гариза**

Сездән ____________________________________________________________
(дәүләт хакимияте башкарма органы гамәлгә ашыра торган
__________________________________________________________________
төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре исеме)
__________________________________________________________________

Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлегенә кертүегезне үтенәм.

Гаризага Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру вәкаләтен бирә торган хокукый актның күчермәсе теркәлә.

Битләрнең гомуми саны _______.

Җитәкче

| | | |
|---|---|---|
| ______________________________ | ____________________ | ______________________ |
| (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы исеме) | (имзасы) | (Ф.И.Ат.ис.) |

Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеген алып бару тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

______________________________
(Татарстан Республикасы
дәүләт хакимияте башкарма
органы исеме)
җитәкчесе __________________________
(фамилиясе, исеме,
атасының исеме)

**Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлегенә кертү турында хәбәрнамә**

Бу хәбәрнамә ________________________________________________________
(дәүләт хакимияте башкарма органы исеме)
гамәлгә ашыра торган ______________________________________________________
(төбәк дәүләт контроле
_____________________________________________________________________________
(күзәтчелеге) төре исеме)

____________ теркәү саны белән Татарстан Республикасында төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлегенә кертүне раслый.

Татарстан Республикасы
икътисад министры ___________________ ___________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)